**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлегенең Шәрләрәмә авылы торак пунктында
2026 елда үзара салым кертү турында

**2025 елның 18 ноябре** **№ 2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Шәрләрәмә авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Шәрләрәмә авылы территориясендә I төркем инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
-Шәрләрәмә торак пунктында электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән тышкы яктырту челтәрләрен (урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру), трансформатор һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка җиһазларны ремонтлау;
-Шәрләрәмә торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);) Мәктәп, Елга, Яшьләр урамнарында юлларны вак таш белән каплауны оештыру(вак таш ташу);
-Ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү( Шәрләрәмә авылы зиратларында зур агачлар кисү);
-Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу, Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу, Речная урамында зур агачлар кисү.

3. Әлеге карарны Шәрләрәмә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Н.Н.Хуҗина